Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының
Кече Талкыш авыл җирлеге башлыгы
Карары

2021 елның 9 апреле № 2

Чистай муниципаль районының Кече Талкыш авыл җирлеге башлыгының 2016 елның 29 апрелендәге 10 номерлы «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Кече Талкыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру, шулай ук Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Кече Талкыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында Нигезләмәне раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

Чистай шәһәр прокурорының 2021 елның 31 мартындагы 02-8-02-2021 номерлы протестын карап чыкканнан соң, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230 номерлы Федераль закон нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. Чистай муниципаль районының Кече Талкыш авыл җирлеге башлыгының 2016 елның 29 апрелендәге 10 номерлы карары «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Кече Талкыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру, шулай ук Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Кече Талкыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында Нигезләмәне раслау турында» карары белән расланган, Чистай муниципаль районының «Кече Талкыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру, шулай ук Чистай муниципаль районының «Кече Талкыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

6 пунктның «в» пунктчасында һәм 12 пунктта «акцияләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләре, пайлар)» сүзләреннән соң «, цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны авыл җирлегендә яшәүчеләрне күпләп җыелган урыннарда, игълан итү стендларында һәм такталарында урнаштырырга, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында http://chistopol.tatarstan.ru/ урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Кече Талкыш авыл җирлеге
башлыгы Г.Н.Федотов